**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 11 ноябрь № 844

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын оештыру һәм үткәрү турында» 2011 ел, 10 июнь, 463 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 август, 625 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге мониторингын гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат кертү регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

11 нче пунктта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору буенча советка аны Совет утырышында карау өчен» сүзләрен «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы тору эшчәнлеген яраштыру буенча комиссиягә аны Комиссия утырышында карау өчен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләрне раслау турында» 2013 ел, 4 апрель, 225 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре бүлекләрен урнаштыруга һәм тулыландыруга карата бердәм таләпләргә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

1 нче һәм 1.1 нче пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору буенча совет» сүзләрен «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы тору эшчәнлеген яраштыру буенча комиссия» сүзләренә алмаштырырга;

1.4 нче пунктның беренче һәм икенче абзацларында «керемнәр» сүзеннән соң «, чыгымнар» сүзен өстәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 14 июнь, 492 нче, 2014 ел, 25 сентябрь, 678 нче, 2014 ел, 9 декабрь, 962 нче, 2014 ел, 31 декабрь, 1090 нчы, 2015 ел, 2 февраль, 54 нче; 2015 ел, 24 апрель, 279 нчы; 2015 ел, 7 август, 576 нчы; 2015 ел, 24 август, 619 нчы, 2015 ел, 26 август, 620 нче һәм 2015 ел, 16 октябрь, 771 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы тору» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 бүлекнең уналтынчы абзацында «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору буенча совет» сүзләрен «Татарстан Республикасында Коррупциягә каршы тору эшчәнлеген яраштыру комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                  И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\844.docx